СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*4 декабрь, 1998 ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* *№ 138 (8295)* *Бәясе билгеләнгәнчә*

# ҮРНӘК ИТӘРГӘ ДӘ, ГЫЙБРӘТ АЛЫРГА ҖИРЛЕК БАР

## Район семинар - киңәшмәсеннән

***Инде хәбәр иткәнебезчә, дүшәмбе көнне шәһәр һәм район хакимиятендә хуҗалык рәисләре, агропромышленность комплексының эшкәртү һәм хезмәт күрсәтү предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре, хакимиятнең бүлек башлыклары, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең баш белгечләре катнашында семинар - киңәшмә булып үтте.***



Хакимият башлыгы Ф.С. Сибагатуллин аны ачканда ук сүзнең терлекчелектә унбер айлык эш нәтиҗәләре турын- барачагын һәм сөйләшүнең гаять җитди булачагын искәртеп үтте. Чыннан да, бу тармакта нәтиҗәләр гаять уйландырырлык. Югыйсә бит, быел һава шартлары барлык хуҗалыкларга да бертөсле килде. Димәк, эш нәтиҗәләрендә дә аермалар әллә ни кискен зур булырга тиеш түгел иде төсле. Әмма чынлыкта хәл бөтенләй башка шул. Хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев ясаган информациядә китерелгән, хакимият башлыгы аңлатмалар биреп барган саннардан бер үк шартларда да теләгәндә эшне үрнәк булырлык иттереп алып барырга мөмкинлеген, теләмәгәндә, күңел итмәгәндә булганны,да әрәм - шәрәм итеп бетерергә бик җиңел булуын күрергә мөмкин иде. Бүгенге кыен шартларда да чын хуҗаларча эш иткәндә нинди нәтиҗәләргә ирешергә, аерым алганда, терлекчелектә тотрыклылыкны сакларга гына түгел, ә фәнчә әйткәндә, киңәйтелгән кабат җитештерүгә дә ирешергә мөмкин булуын семинарда катнашучылар "Өмет" агрофирмасы кооперативларында ачык күрделәр. Бу хуҗалык турында әледән - әле язып торганга, андагы фермалардагы үрнәк тәртип, чисталык, технология таләпләренең җиренә җиткереп үтәлүенә җентекләп тукталып тормыйбыз - анысын булган кеше үз күзләре белән күрде. Бары тик берничә моментка гына аерым басым ясап үтәсе килә.

Мәгълүм булганча, агрофирма сөт җитештерү буенча алдынгылыкны тоткан Мичурин исемендәге һәм дуңгызчылык тармагы киң үсештә булган Кузнецов исемендәге хуҗалыкларны берләштереп оештырылды. Һәм бүген хуҗалыкның барлык кооперативларында да бер генә тармакта да әллә ни зур аерма сизмисең инде - барлык фермаларда да чын хуҗа кулы ярылып ята. Һәркайда малларны бәйләүсез һәм бәйләүдә асрау алымнары уңышлы чиратлаштырып кулланыла, бозаулату абзарларында тулы тәртип, яшь үрчем беренче тәүлектә әнкәсе янында тотыла да (анда да салкын метод), шулай ук салкын метод буенча асрауга күчерелә. Алларында яшь терлекләргә тиеш һәм кирәкле булган барлык төр витаминнар да бар. Үстерү һәм симертү группалары асрала торган абзарларда да бәйләүсез асрау алымы уңай нәтиҗәсен бирә. Буаз таналар аерым игътибар үзәгендә. Шунысын да әйтергә кирәк, савым көтүенең киләчәге буласы ул малларны биредә кайбер хуҗалыклардагы кебек иясез калдырмыйлар, ә аерым абзарларда тиешле рацион буенча ашатып тоталар. Ул гына да түгел, кооперативлар арасында специальләшү системасы кертеп, берәрсенә нәкъ менә таналар әзерләүне йөкләргә булганнар. (Заманында таналарны юнәлешле үстерү белән шөгыльләнгән Мичурин исемендәге хуҗалыкта андый тәҗрибәгә кытлык юк та юк инде). Сүз уңаеннан, бу хуҗалыкта теге яки бу тармакка җитди эш итеп карауларын кооперативлар арасында әледән -әле үзара тикшерүләр, фикерләшүләр оештырып торуларыннан да чамаларга мөмкин. (Ә бит кайбер хуҗалыкларда ай саен уздырылырга тиешле терлекчеләр көне кайсы елны уздырылганлыгын да хәтерләмиләр инде).

(Ахыры 2нче биттә).

## 12 ДЕКАБРЬ ШӘҺӘР КӨНЕ

### *Хөрмәтле нурлатлылар!*

***12 декабрь көнне ипподром мәйданында "Шәһәр көне"нә багышланган зур бәйрәм була.***

***Бәйрәмнең программасы түбәндәгечә:***

***1. Бәйрәмне тантаналы ачу.***

***2. Спорт ярышлары һәм спорт - күңел ачу уеннары.***

***3. Нурлат шәһәре призына Мәскәү, Казан, Түбән Кама, Яр Чаллы, Тольятти, Ижевск, Ульяновск, Самара шәһәрләреннән Россиянең иң көчле спортчылары катнашында кышкы трек автомобиль узышлары.***

***4. Сәүдә предприятиеләре - Нурлат район куллан учылар җәмгыяте, "Нурлатнефть" НГДУсы, тимер юл һәм урман хуҗалыгы эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре, район хуҗалыклары һәм предприятиеләре кибетләре, шәхси эшмәкәрләр, җәмәгать туклануы предприятиеләре сатучылары катнашында зур ярминкә. Бәйрәм 9.00 сәгатьтә башлана.***

***Алдагы көнне - 11 декабрьдә автоузышларда катнашучылар өчен контроль үтү билгеләнә.***

***Хөрмәтле нурлатлылар, кунаклар! Шәһәр көненә рәхим итегез!***

*Инвалидлар уңкөнлеге бара*

## ТЕЛӘСӘҢ, МӨМКИНЛЕК ТАБЫЛА

Замана авыр дибез дә, җаныбызның бар кырыслыгын, игътибарсызлыгыбызны шуның белән аклыйбыз да куябыз. Юкса, нәкъ менә замана авыр чакта аерата тансык бит ул кешелеклелек дигән нәрсә. Кызганыч, еш кына бу хакта истән генә чыгарып җибәрәбез.

Ә менә "Нурлат" агрофирмасы ит комбинатында эшләп чыккан өлкәннәрдән җитәкчелек адресына үпкә сүзе һич ишетмәссең. Үпкәләргә урыннары юк аларның, һәрдаим игътибар тоеп торалар. Мәсәлән, күптән түгел генә администрация коллектив килешүгә минималь пенсия алучы пенсионерларга коммуналь түләүләрнең бер өлешен предприятие хисабына каплау һәм квартал саен минималь пенсиянең 50 процентын күләмендә матди ярдәм күрсәтү турында өстәмә кертергә карар кылды. Комбинат һәр елны өлкәннәр һәм инвалидлар көнен дә зурлап билгеләп үтә. Быел 1 октябрьдә, мәсәлән, 70тән артык пенсионер өчен мул аш табыны әзерләнде, һәрберсенә 100әр сумлык азык - төлек җыелмалары тапшырылды. 15 ноябрь, авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү промышленносте хезмәткәрләре көнне дә пенсионерлар, эшләүчеләр белән беррәттән, 80шәр сумлык азык - төлек җыелмалары алдылар.

Ит комбинаты инвалидлар декадасына да күз йомып кына калмады. 2 декабрь көнне ашханәдә әлеге категория кешеләр өчен аш табыны әзерләнде, ә киткәндә һәрберсенә азык - төлек, кер юу средстволары тутырылган пакетлар тапшырылды. Кунаклар мондый игътибардан бик канәгать калдылар, предприятие җитәкчелеге, профсоюз комитетына рәхмәтләр укыдылар.

** Сәнгать дөньясыннан*

## КОМПОЗИТОРНЫ КОТЛАУ

Узган якшәмбе көнне Казанда ТРның Дәүләт концерт залында Композитор Мирсәет Яруллинның 60 еллык юбилее уңаеннан иҗат кичәсе булды. Анда юбилярга нурлатлылар һәм район хакиме исеменнән котлауларны хакимият йөкләве буенча сәнгать мәктәбе директоры Т.С.Бадыйгин җиткерде.

## ДУСЛЫК УРНАШЫР,АХРЫ

Чаллы җырчысы Виталий Агапов сәнгать мәктәбе белән якты бәйләнеш урнаштырырга җыена. Бу юлы Нурлатка концерт белән килгәч, мәктәп коллективына җыр җыентыкларын бүләк итте, махсус килеп, яңа мәктәп, укытучылар белән танышып чыкты, киләчәктә биредә очрашу оештырырга вәгъдә итте.

## ОЧРАШУ КӨТЕЛӘ

Ә менә РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты, Санкт - Петербургта яшәп иҗат итүче Альберт Әсәдуллин белән очрашу шушы көннәрдә үк булыр дип көтелә. Альберт әфәнде Нурлатта концерт буласы көнне - 5нче декабрьдә сәнгать мәктәбе укучылары һәм ата - аналар өчен очрашу концерты бирәчәк. Ул 15.00 сәгатьтә сәнгать мәктәбенең концерт залында үтәчәк. Талантлы милләттәшебез белән очрашуны һәркем зур бәйрәм итеп кабул итәр, дип уйлыйбыз.

*Республика сулышы*

## БЕЗНЕКЕЛӘР - "ИНТЕРНЕТ"ТА

***Татарстан Язучылар берлеге турындагы мәгълүматлар "Интернет" халыкара челтәренә кертелде.***

Сәхифәне Микаил Башту ибн Шамс Габделләх әт Тибир әл Болгариның "Шан кызы" дастаны ачып җибәрә. Шунда ук Колгали, Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Шәехзадә Бабич, Муса Җәлил; замандашларыбыздан Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев һәм башкалар урын алган.Исемлектә татар классик әдәбиятын тәшкил иткән 500дән артык әсәр санала.

## "ЭФИР" ЮГАРЫЛЫКТА

***Россиядәге региональ телекомпанияләр арасында безнең "Эфир" телекомпаниясе иң яхшысы дип табылды һәм диплом белән бүләкләнде.*** Телекомпания журналистлары эшенең һәрвакыт кызыклы һәм тормышчан булуы югары бәяләнде.

## «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛУ БАРА

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

# 16 ЯШЕҢ ТУЛГАЧ...

Соңгы елларда Россия гражданнарының хокуклары һәм ирегe турында дәүләт дәрәҗәсендә берничә закон һәм норматив актлар кабул ителгән иде. Аерым алганда, 1997 елның 13 нче мартында "Гражданның шәхесен билгели торган төп документ турында" Президент Указы чыкты. Ә 1997елның 18нче июнендә РФ хөкүмәте РФ гражданының паспорты, бланк үрнәге һәм паспортның бирелү - алмаштырылу вакыты, учетка алынуы, саклану тәртипләре турындагы Положениене раслаучы карар кабул итте.

Бу законнарда паспортның РФ территориясендә РФ гражданының шәхесен танытучы төп документ булуы күрсәтелә. РФ территориясендә яшәүче 14 яше тулган һәр гражданның паспорты булырга тиеш.

Безгә еш кына нигә 14 яшьтән поспорт бирелми дигән сораулар бирелә. Мәгълүм булганча, Татарстан - Россия составындагы суверен республика, шуңа күрә законнар чыгару һәм башка мәсьәләләр ТР вәкаләтенә бирелгән. Шунлыктан Татарстан Дәүләт Советы безнең республикада "Татарстан Республикасы гражданлыгы турында" закон кабул итмичә Россия гражданнарына паспорт бирүне туктатып торырга карар кылды. Ә ул әлегә беренче укуда гына кабул ителгән. Шуңа күрә бездә бүгенгә 16 яшьтән һәм РФ гражданлыгына керүе күрсәтелә торган иске үрнәктәге паспортлар бирелә. Бу докуменлар 2005 елга кадәр гамәлдә. Димәк, безнең республиканың 16 яшькә җиткән барлык гражданнары да паспортлы булырга тиеш. Паспорт алу өчен коммуналь фатирларда яшәүчеләр үзләренең ЖКХларына туу турында таныклык, 6га 7 см.лы 3 фоторәсем, тору урыны буенча теркәлү өчен дәүләт пошлинасы түләү турында квитанция тапшырырга тиешләр. Ә паспортны Нурлат эчке эшләр бүлегенең паспорт - виза хезмәте бүлегендә ала алалар. Шәхси йортларда яшәүчеләргә дә шул ук документлар һәм паспорт алуга гариза белән кабул итү сәгатьләрендә шунда ук килергә мөмкин.

Шул мәсьәлә буенча минем ата-аналарга, мәктәп һәм ПТУ администрацияләренә мөрәҗәгать итәсем килә. Күп вакыт паспорт алу өчен безгә укырга яки эшкә китәр алдыннан гына мөрәҗәгать итәләр. Ә бит паспорт җитди документ, һәм аны рәсмиләштерү өчен аз вакыт кирәкми.

Без шәһәрнең 1, 4нче мәктәпләрендә паспортны тантаналы рәвештә тапшыру традициясен дәвам итәләрдер дип ышанабыз. Бәлки ул башка мәктәпләрдә дә яшәеш алыр.

**М. ГЫЙРФАНОВ,**
**район паспорт - виза хезмәте бүлеге начальнигы, милиция майоры.**

## СӨЮГӘ ХЫЯНӘТ ИТМӘГЕЗ!

Көз - елның моңсу вакыты. Шул көз айларында ир - егетләребез армия сафларына чакырыла. Туган җиреннән, авылыннан еракка чыгып йөрмәгән 18 яшьлекләр төрле тарафка таралалар. Әти - әни өчен баласын күз күрмәгән якка чыгарып җибәрүдән дә газаплы нәрсә юк ул. Күп егетләрне хәрби хезмәткә ата - ана белән янәшә басып, сөйгән кызы озата. Аерылганда туктаусыз аккан күз яшьләре, "көтәрмен" дигән вәгъдәләр...

... Исән кеше өчен 2 - 3 ел гомер уза да китә ул. Аннан соң кабат туган җир дәшеп кайтара. Әмма кайбер кызларның егетләрен көтеп алырга көчләре җитми. Юк, мин беркемне гаепләргә теләмим, әмма солдатны, хисләренә тугры калып ана гына көтеп ала. Мин беләм, сөю кешегә яшәргә, шатланырга ярдәм итә. Димәк, кайнар ноктaларда хезмәт иткәндә дә егетләр сезнең яратуны тоеп яши. Бу җиһанда сөю гомер - гомергә изге, кадерле хис булган. "Яратам! Көтәм!" сүзләрен әйтер алдыннан уйланыгыз: көтә алырсызмы, чынлап яратасызмы? Мин шундый вәгъдәгә хыянәт итүне күрдем. Егетен озаткан кыз берничә ай узуга башка берәү белән йөри башлады... Кайберәүләр бу югалтуны авыр кичерә, эчүгә сабыша, хәтта үз - үзенә кул сала...

Бу хат юллары аша бер генә теләк телисе килә кызларга. Каермагыз егет канатын! Сөюегезгә ышанычыгыз булмаса, вәгъдә биреп озатмагыз аларны. Хыянәт итмәгез сөюгә!

**Л.ДАУТОВА.**

## ОЧРАШУГА МАЙОР КИЛДЕ

Узган атнада 4нче мәктәпнең милиция - лицей класслары укучылары белән очрашуга ТР Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаганнар арасында җинаятьләрне кисәтү идарәсе хезмәткәре милиция майоры Р.Р.Зарипов килде. Ул милиция хезмәткәрләренә җәмгыятебез йөкләгән зур бурычларга тукталды, укыту - тәрбия эше тиешенчә оештырылсын өчен лицей классларына матди ярдәм күрсәтеләчәгенә вәгъдә бирде.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП...



## ХИСЛӘНДЕК ТӘ, СӨЕНДЕК ТӘ

28 ноябрь көнне Чулпан урта мәктәбенә 3нче һәм 4нче класс укучылары чакыруы буенча әниләр көнен билгеләп үтәргә җыелдык. Әни булып, кунак булып кына утырмадык без анда, ә бәлки балаларыбыз белән бергә балачакка да кайтып килгәндәй булдык.

Әниләр һәм балалардан торган катнаш 2 командага бүлендек, аларга "Ялкын" һәм "Чулпан" исемнәре куштык, эмблемаларын да ясадык. Кызыклы табышмаклар һәм башваткычлар әйтү, әниләр турында җырлар җырлау буенча да, 3 яшьлек бала булып уйнап күрсәтү, бишек җыры җырлап бала йоклату, күзне каплап керләр элү, техтага әни сурәтен ясау, чәч үрү буенча ярышу дисеңме - гомумән, нинди генә уеннар уйнамадык без кичәдә! Ярыш ахырына колак яфракларыбыз кызарган, битләребез алсуланган, күзләребез очкынланган икәнлеген күреп бер - беребездән көлештек тә әле.

Ярыш булгач, аның җиңүчесе дә була инде. Жюри эшен мәктәпнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Татьяна Геннадьевна Прокопьева бик җитди һәм төгәл алып барды һәм очколар суммасы буенча "Ялкын" командасын җиңүче дип игълан итте.

Аннан соң "Иң олы әни", "Иң яшь әни", "Иң озын толымлы әни", "Иң нечкә билле әни", "Иң сипкелле әни", "Иң зәңгәр күзле әни" исемнәренә конкурслар үткәрелде, җиңүчеләргә символик медальләр тапшырылды.

Без, әниләр, балаларыбызның безне сурәтләгән рәсемнәр күргәзмәсен карап та, безнең турында язган сочинениеләрен укып та бик хисләндек һәм сөендек.

Соңыннан без матур җырлар тыңлап, үзебез пешереп килгән тәмле - тәмле пироглар, тортлар, чәкчәкләр, прәнникләр белән сыйланып,сөйләшә - сөйләшә чәй эчтек, төрле - төрле салатлардан авыз иттек. Безнең өчен искиткеч күңелле, чын бәйрәм оештыручы хөрмәтле укытучыларыбыз Рәзилә Шакировна һәм Рәмзия Хәмитовна Вәлиәхмәтоваларга чын күңелдән рәхмәтләребезне әйтеп таралыштык ул көнне.

"Әни" бәйрәме түгел, "Әни һәм бала" бәйрәме булды ул, безне балаларыбыз белән тагын да якынайтты, берләштерде. Гомергә шулай булсын иде!

**Д.ШӘЯХМӘТОВА.**
**Чулпан авылы.**

## СОРАГЫЗ - ҖАВАП БИРӘБЕЗ

***Редакция адресына юлланган берничә сорауга җавап бирүен үтенеп, без район кулланучылар хокукларын яклау комитеты рәисе Р.СУФИЯНОВка мөрәҗәгать иттек.***

### ИПИ БҮЛЕП ТӘ САТЫЛА

**"Мин үзем генә торам, шуңа да бер данә ипи минем өчен күп була. Кайчак сатучылар миңа ипине бүлеп сатырга авырсыналар. Ипи бүлеп сатылырга тиешме?**

**Мәрьям.**
**Нурлат шәһәре".**

- 400 граммлы һәм аннан да артык авырлыктагы ипи һәм икмәк - күмәч әйберләрен сатып алучы үтенече буенча ике яки дүрт өлешкә бүлеп сатарга мөмкин. Бу очракта аларны үлчәп тору мәҗбүри түгел.

### КИРЕ КАЙТАРЫЛМЫЙ

**"Азык - төлеккә дә бәяләр гел үзгәреп тора. Сатып алучы элек алган ашамлык продукциясен бераз вакыт үткәч кибеткә тапшыра аламы?**

**Ә.С.**
**Нурлат."**

- Азык - төлек әйберләрен сатып алып күпмедер вакыт үткәч кире кайтару рөхсәт ителми. Бары сатып алынган товар сыйфатсыз булган яки куллану срогы чыккан очракта гына кире алына.

*Сорау - җавап*

## ТЕЛЕФОН ТУРЫНДА ГЫНА

### ЛЬГОТАЛАР ТҮЛӘНӘ, ӘММА СОҢГА КАЛЫП...



***"Инвалидларны социаль яклау турында"гы (4нче ноябрь, 1995 ел) 181нче Федераль Закон нигезендә мин, хезмәт инвалиды буларак, телефонга түләү буенча льготадан файдаланырга тиешлемен. Ләкин мондый бәхеткә ирешкәнем юк әлегә. Ни өчен бу закон үтәлми икән?***

***ПОРТНОВ.***
***Нурлат шәһәре."***

***Без бу сорау белән район электр элемтәсе узеленың хисаплау буенча операторы Н.Г.ФӘССАХОВАГА мөрәҗәгать итеп түбәндәге җавапны алдык.***

- "Ветераннар турында" Федераль Закон 1996 елның 6нчы маенда чыкты, ә аның нигезендә шул ук елның 30 нчы сентябрендә ТР ның Министрлар Кабинеты да тиешле карарын чыгарды. Анда ветераннар һәм инвалидларның кайбер категорияләренә телефон хезмәтләре өчен түләүдә 50 процент ташлама каралган. Төгәлрәге, сугыш инвалидлары һәм сугышта катнашучылар, Социалистик Хезмәт Геройлары, сугышта һәлак булучыларның гаиләләре, сукырлар җәмгыяте әгъзалары, I - II группа инвалидлар, Совет Армиясе, эчке эшләр министрлыгы инвалидлары, Әфган сугышында булучылар. Әмма быелның октябрь азагына кадәр җирле бюджеттан бер тиен дә акча күчерелмәгәнлектән, әлеге мәсьәләдә бик күп аңлашылмаучылыклар килеп туды. Еш кына льготаларны бездән таләп итеп, үпкәләрен безнең адреска белдерүчеләр бар. Без, үз чиратыбызда, тулысынча түләп торырга өндибез, акча күчерелгәч, тиешле сумма кире кайтарылачак, дип аңлатырга тырышабыз. Һәм октябрь аенда шулай булды да. Җирле бюджеттан ярты еллык льгота суммасы күчерелде һәм алда саналган категория гражданнар белән исәп - хисап ясалды. Калган айларга льготаларның кайчан биреләсен без төгәл әйтә алмыйбыз.

***- Наилә Габбасовна, район элемтә узелында телефонга абонемент түләү буенча льготаларның бирелү тәртибе турында да сөйләп үтегез әле.***

- Льгота алырга тиешле кеше социаль тәэминат идарәсендә теркәлә, моның өчен үзе белән паспорт, йорт кенәгәсеннән үзенең (яки гаилә әгъзасының, телефон аның исеменә рәсмиләштерелгән булса) яшәү урыны турында күчермә булырга тиеш. Шулар нигезендә, социаль тәэминат бүлеге льгота алучылар исемлеген төзи һәм РУЭСка тапшыра. Бүгенге көндә исемлектә район буенча барлыгы 623 кеше исәпләнә. Бездән ул исемлек район финанс бүлегенә тапшырыла. Аннан акча күчсә, элемтә узелында бернинди тоткарлык булмаячак.

## ҺӘЙКӘЛГӘ ЧӘЧӘКЛӘР КУЕЛЫРМЫ?

1999 елның 15 февралендә Әфганстаннан совет гаскәрләрен чыгаруга 10 ел тула. РФ Президенты каршындагы җаваплы комиссиядән ТР Президентына килгән хаттан аңлашылганча,бу датаны онытмау һәм лаеклы рәвештә билгеләп үтү күздә тотыла. Шул документның бер нөсхәсен вице - премьер А.Конюшева Нурлат районы хакимиятенә дә җибәргән. Анда Әфганстанда һәлак булганнарның гаиләләре һәм конфликтта катнашучылар һәм инвалидларның хәл ителмәгән социаль проблемаларына һәм медицина хезмәте күрсәтүгә барлык төрдәге власть һәм идарә органнарының игътибарын җәлеп итү сорала, хәрби - патриотик тәрбияне көчәйтү һәм һәлак булганнарның исемнәрен мәңгеләштерү мөһимлеге турында әйтелә.

Безнең районда бүгенгә Әфганстан сугышында катнашкан 145 кеше яши, ә 5се анда һәлак булды. Исәннәре социаль ярдәмгә мохтаҗ, әлбәттә. Ә һәлак булганнарның исемнәрен мәңгеләштерүгә килгәндә, берничә ел элек әфганчылар инициативасы белән Кормыш микрорайонында һәйкәл торгызыла башлаган иде, ләкин аны ахырына кадәр төзеп ачырга һаман да насыйп булмады.Түгәрәк дата уңаеннан бәлки, шул һәйкәл бусагасына чәчәкләр куярбыз?

**Ф. ГАЛИМОВА.**



*Вакытлы матбугатка язылыр чак*

# «КИҢӘШ»ТӘН ЗУР ТАЯНЫЧ БАРМЫ?

Бу болгавыр заманда киңәшсез яшәү җиңел түгел. Авыр чакта туганыңа, дустыңа гына түгел, күршеңә булса да киңәшкә керәсең. Акыллы, төпле киңәш бирерлек күршегез, туганыгыз, дустыгыз булмаса, аптырап калмагыз. Татарстанда нәшер ителә торган "Киңәш" гәзите редакциясенә генә языгыз. "Киңәш" гәзите - үз эченә мең дә бер киңәшне сыйдырган файдалы көндәлек кулланма. Киңәшне табыш итәсегез килсә, "Киңәш" гәзитенә язылып карагыз. Юристлар һәм табиблар, бакчачылар һәм аш - суга оста хуҗабикәләр, белгечләр һәм аксакаллар сезнең иң якын киңәшчегезгә әверелер. Киңәштән зур таяныч юк, ди халык. Йөзләгән укучы "Киңәш" гәзите аша күп төрле соравына җавап таба, ярдәм ала. "Киңәш" гәзите "Юлдаш" гәзите кебек үк укучыларның таянычы, ярдәмчесе, юлдашы. "Киңәш" белән киңәшегез.

Аның каталогтагы индексы - **54147.** Татарстанда 1999 елның яртысына язылу бәясе - 12 сум. "Киңәш"кә быел да язылып була. 1 айга язылу хакы - 1 сум 60 тиен генә.

Хатларыгызны, юристка сорауларыгызны түбәндәге адрес буенча юллый аласыз: ***423805, Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан урамы, 23, а/я 53.***

**Г.ВӘЛИДИ,**

**"Киңәш" гәзитен оештыручы һәм гамәлгә куючы.**

# ТӨРЕК ХАТЫННАРЫ ИРЕН ҺӘМ ГАИЛӘСЕН СӨЯ

Төркиядә, 1997 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча, якынча 63 миллион кеше яши. Шуларның яртысын хатын - кызлар тәшкил итә. Аларның 60 проценты - 16 - 64, 34 проценты - 1 - 15 яшьтәгеләр, калганнарын 65 яшьтән олыраклар тәшкил итә.

Төрек кызлары, уртача алганда, 22 яшьтә кияүгә чыга, 20 яшь тулганчы ир хатыны булучылар саны 31,8 процненттан артмый. Үзләре теләп кияүгә чыгучылар шәһәрдә 29,5, авыл җирендә 19,3 процент тәшкил итә. Гадәттә, кызлар ата - ана тәкъдим иткән кешегә кияүгә чыга.

Аерылышуга килгәндә исә инициатива - хатын - кызлар кулында. Суд эшләренең 59,9 проценты нәкъ менә алар тарафыннан кузгатыла. Аерылышуның беренче сәбәбе "тынышмау". Иң күп аерылышулар өйләнеп торуның 1 - 5 елларына туры килә. Бергә яшәү вакыты һәм балалар саны арта барган саен аерылышучылар саны да кими. Төркиядә бер хатын - кыз уртача 3,7 бала таба. Бу күрсәткеч авылларда югарырак.



Гаилә эчендә хезмәтнең бүленеше, йөкнең авыры - һаман да хатын - кыз өстендә. Ризык пешерү, ашарга әзерләү, өйне чиста тоту, савыт - саба һәм кер юу, үтүкләү кебек традицион өй эшләрен тулаем алар башкара. Шул ук вакытта, хатын - кызларның гаилә бюджетына да зур өлеше керә.

Хатын - кызларның 46 проценты ирләрне үзләреннән акыллырак, дип саный. Җитди сәбәп булганда, ирләр хатыннарын кыйнарга хаклы, дип уйлаучылар - 50 процент тирәсендә. Хатын - кызларның 54,8 проценты "ир кеше теләгән вакытында дуслары янына барып килә ала, моның бернинди зарары юк", дигән фикердә тора. Төркиядә хатын - кызларның 30 проценты гына эшли. Хезмәттәге һәр 100 хатынның уртача 75е - авыл хуҗалыгы тармагында, алтысы - фәнни һәм техник хезмәткәрләр һәм ирекле һөнәр ияләре, бишесе идарә органнарында исәпләнә.

Төркия Бөек Милләт Мәҗлесендә (парламент) хатын - кызлар бик аз. 1935 елда парламентка 18 хатын - кыз сайланды, ләкин аннан соңгы елларда депутат хатын - кызларның саны бу күрсәткечтән түбән булды. 1995 елда ТБММ га 13 ханым сайланды (бөтен депутатларның 2,36 проценты). Аларның күбесе югары белемле, теге яки бу һөнәр иясе, чит телләрне белә. Аурупа илләрендә депутат вазифасын башкарган хатын - кызларның саны Төркиягә караганда күпкә артык. Мәсәлән, Швеция парламентында депутатларның 40 процентын хатын - кызлар тәшкил итә. Швециядә хатын - кызлар, гомумән, иң киң хокукларга ия. Икенче урында - япон хатын - кызлары.

**Айшә ПАКДИЛ.**

**("Заман Татарстан" нан).**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары Нурлат авылында яшәүче **кадерле тормыш иптәшем, әтиебез, дәү әтиебез Миннасыйх Хәммәткәрим улы Әхмәтсафинны** юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз.



Чәчләреңне, әткәй чал басса да,
Күңелең иркен, һаман яшь әле.
Җаның тыныч, тәнең таза булсын,
Кайгы - хәсрәт күрми яшә әле.

**Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, улың, киленең, оныкларың: Илмир, Артур.**

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## САТАБЫЗ

**Южный тыкрыгы 1 - 2 адресы буенча өч бүлмәле фатир.** Тел.: 5-42-90.

***

**Ясалма мехтан сырылган яңа тун.** Тел.: 5-16-58.

***

**Совет ур., 193 йортының 2нче катында бер бүлмәле фатир.** Тел.: 5-42-38.

***"Евразия" сәүдә үзәге***

***( К.Маркс ур., 51а йорты, саклык банкы белән Яшьләр үзәге арасында) Сезне теле, видео, аудио көнкүреш дөньясына чакыра. Сезгә киң ассортиментта дөньяның әйдәп баручы фирмалары җитештергән техника тәкъдим ителә. Алардан "Сони", "Панасоник", "Самсунг", "Шарп", "Тошиба" үзләрен дөньяда югары сыйфат гаранты буларак таныттылар. Сезне көн саен иртәнге 9дан кичке 6га кадәр көтәбез. Төш вакыты көндезгә 1дән 2гә.***

Тел.: 2-14-30.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

***Аяк киемнәренә ашыгыч ремонт (53нче СМУ бинасында). В - 98 сер. № 060431 лицензия.***

# КАРТАЙМАУНЫҢ ТӘМЛЕ ЫСУЛЫ

АКШның Милли фәннәр академиясе экспертлары урта яшьтәгеләр арасында еш очрый торган вакытыннан элек картаю һәм аз канлылык кебек авыруларны кисәтүнең нәтиҗәле, ә иң мөһиме - гади һәм тәмле ысулларын уйлап тапканнар. Моның өчен балык ашларын һәм сөт ризыкларын ешрак ашарга кирәк икән.

Белгечләр шулай ук ярты гасырлык юбилейларын билгеләп үтүчеләргә В төркеменә керүче витаминнар хакында да онытмаска киңәш итә.

("Шәһри Казан"нан).

**01 ХӘБӘР ИТӘ**

# НОЯБРЬДӘ ДӘ ЯНДЫК

Ноябрьнең 24ендә килеп чыккан янгын Нурлатта яшәүче Х. гаиләсе өчен фаҗига белән бетте. Хуҗа хатын, өч яшьлек малаен һәм бер яшьлек кызын өйдә үзләрен генә калдырып ишегән бикләп беразга гына кибеткә дип чыга. Балаларга үзләре генә утыру күңелсез булып китә һәм алар... шырпы белән уйный башлыйлар. Нәтиҗәдә түшәккә ут каба... Балаларны коткарып калып булмый.

Шул ук көнне шул ук сәгатьтә Молодежная урамындагы 4нче йортта торучылардан берсенең ут белән саксыз эш итүе аркасында бер фатирда янгын чыга. Күршеләре чакыртып китергән янгын сүндерүчеләр утка ирекенләргә ирек бирмиләр.

29 ноябрьдә Егоркино авылында янгын чыкты. Төтен юлының төзексезлеге аркасында А.Магинның мунчасы янып бетте.

# АЧУ ЧЫККАН ЧАКТА

Әдәплелек кагыйдәләре үзеңне һәрвакыт кулда тотуны таләп итә: пыр тузып кычкырышырга теләгән вакытларыңда да дәшми каласың. Синең нервыңда уйнаган адәмгә карап ягымлы елмаясың... Әмма соңыннан үтереп - үтереп ашказаны бора башлый, кан басымы күтәрелә, радикулит тотып ала.

Белгечләр исәпләвенчә, стресс хәлендәге кеше эчендә булган бөтен парын чыгарып бетерергә тиеш икән. Моның өчен күп кенә алымнар да уйлап табылган. Мисал өчен, Америка халкы үзенең ачуын яраксызга чыгарылган иске автомобильләрдән ала. Каны бик нык кызган кеше "машиналар каберлеге"нә бара һәм кулына эләккән иң беренчесен зур чүкеч белән рәхәтләнеп кыйный. Японнар цехка керә торган ишек төбенә резина курчак куялар һәм, күз алларына цех мастерын китереп, әлеге курчакны чын күңелдән тукмыйлар. Ә немецлар пластилиннан хәтерләрен калдыручының фигурасын әвәлиләр, аннары инде аны күңелләре булганчы бармаклары белән изәләр. Бездә исә мондый ысул киң таралган: чиста кәгазь битенә: "Әгәр ачуың чыкса, мине йомарла да почмакка ат",- дип язып куясың. Һәм җене чыккан саен кәгазьдә язылганны үтисең. Әйтергә кирәк, әлеге гап - гади ысул киеренкелекне бетерүдә ярыйсы гына ярдәм итә. Психотерапевтлар түбәндәге кагыйдәләрне дә истән чыгармаска киңәш итәләр: әңгәмәдәшең никадәр катырак кычкырып сөйләшсә, син аңа шулкадәр акрынрак һәм тынычрак җавап бирергә тиешсең.

**("Шәһри Казан"нан).**

**СПОРТ СПОРТ**



# БАСКЕТБОЛНЫ ЯРАТАЛАР



27 ноябрьдә балалар - яшүсмерләр физик тәрбия клубында ДЮКФП һәм Мамык урта мәктәбенең өлкән класс укучылары арасында баскетбол буенча иптәшләрчә очрашу булды.

Баскетболның мавыктыргыч һәм бик кызыклы уен икәнлеген тагын бер тапкыр күрсәтте бу очрашу. Уен Мамык командасы ( тренерлары Н.Н.Багаев) файдасына тәмамланды. Игорь Бондаревның нәтиҗәле уенчы, Алексей Багаев иң яхшы һөҗүмче дип табылдылар. Владимир Дмитриевның оста уйнавын да билгеләп үтми мөмкин түгел.

**Ф.САФИН,**

**ярышның баш хөкемдары.**

## ТАБЫЛДЫКЛАР ӨСТӘЛЕ

**Хаким Әһлиулла улы Шәймәрданов исеменә паспорт табылды.**

Богдашкинода Еруслановка мөрәҗәгать итәргә.



## *"ЫШАНЫЧ ТЕЛЕФОНЫ"*



25 ноябрьдән Нурлат шәһәр һәм район эчке эшләр бүлегендә теге яки бу сәбәп аркасында кем икәнлекләрен белгертергә теләмәүчеләрдән хәбәрләр алу өчен "ышаныч телефоны" эшли башлый. Бер үк вакытта милициянең эшендә нәтиҗәлелекне күтәрү буенча тәкъдимнәр дә көтәбез.

"Ышаныч телефоны" аша алынган мәгълүматлар җинаятьләрне ачу һәм тикшерү, милиция эшендәге җитешсезлекләр һәм негатив фактларны ачыклауда кулланылачак.

***"Ышаныч телефоны"ның номеры 2-12-30.***

Әлегә ул иртәнге 9дан 11гә кадәр һәм көндезге 3тән 5кә кадәр эшли. Алга таба аның тәүлек буе эшләве дә күздә тотыла, ул хакта аерым хәбәр ителәчәк.

Абонентның кемлеген сер итеп саклау гарантияләнә!

***Эчке эшләр бүлеге штабы.***

МӨХӘРРИР
**С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясендә офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4651